| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ШУБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ШУБАН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«24» февраля 2021г.

КАРАР
№2

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион уздырмыйча урнаштыруга шартнамә төзү турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион уздырмыйча урнаштыруга шартнамә төзү турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет ресурсында бастырырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шубан авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Мөҗипов.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты
карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион уздырмыйча урнаштыруга шартнамә төзү турында Нигезләмә

## ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион уздырмыйча урнаштыру тәртибе (алга таба - Тәртип) «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары белән расланган Муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе нигезендә эшләнде.

2. Әлеге Тәртип муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга карата төп таләпләрне билгели.

3. Әлеге Тәртиптә стационар булмаган сәүдә объекты дигәндә, инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташу (технологик тоташтыру) булуга яисә булмавына карамастан, җир кишәрлеге белән нык бәйле булмаган вакытлы корылмадан яисә вакытлы конструкциядән гыйбарәт сәүдә объекты, шул исәптән күчмә объект аңлашыла.

4. Әлеге Тәртип нигезләмәләренең сәүдә объектларын урнаштыру һәм аларның эшләве өлешендә гамәлдә булуы түбәндәгеләргә кагылмый:

1) биналарда, төзелешләрдә һәм корылмаларда урнашкан стационар булмаган сәүдә объектларына;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (алга таба - җирле үзидарә органнары) законнары нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары яисә вәкаләтле вәкилләр карары буенча уздырыла торган яисә алар белән билгеләнгән тәртиптә килештерелгән массакүләм бәйрәм, иҗтимагый-сәяси, мәдәни-массакүләм һәм спорт-массакүләм чараларына сәүдә хезмәте күрсәтүгә, шулай ук ярминкәләрдә товарлар сатуга бәйле мөнәсәбәтләргә.

5. Стационар булмаган сәүдә объектларының төрләре:

павильон - сәүдә залы булган һәм сатучыларның бер яисә берничә эш урынына исәпләнгән, ябык мәйданлы аерым төзелештән (төзелешнең бер өлешеннән) яисә корылмадан (корылманың бер өлешеннән) торган стационар булмаган сәүдә объекты (100 кв. м. га кадәр). Павильонда товар запасын саклау өчен бүлмәләр булырга мөмкин;

Товарны һәм җиһазларны бушатуны автомобильләрне тротуарга кертмичә башкарырга кирәк.

9. Урнаштырыла торган тационар булмаган сәүдә объектлары (хезмәт күрсәтү объектлары) янгын һәм медицина транспортың, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының транспорт чараларының гамәлдәге биналар, төзелешләр һәм корылмалар янына узуга комачауламаска тиеш.

10. Стационар булмаган сәүдә объектлары янындагы территория кичке вакытта яктыртылырга тиеш.

11. Стационар булмаган сәүдә объектларының оешманың фирма атамасы, эш режимы, урнашу урыны, юридик адресы күрсәтелгән элмә тактасы булырга тиеш.

12. Стационар булмаган сәүдә объекты (хезмәт күрсәтү объекты) янындагы территорияне җыештыру гамәлдәге төзекләндерү кагыйдәләре һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге өлкәсендәге таләпләр нигезендә башкарылырга тиеш.

Товарны, төрелмәләрне, чүп-чарны төзекләндерү элементларында, стационар булмаган сәүдә объектларының (хезмәт күрсәтү объектларының) түбәләрендә һәм алар янәшәсендәге территориядә туплау рөхсәт ителми.

13. Стационар булмаган сәүдә объектлары янында сәүдә-суыткыч җиһазлары урнаштыру рөхсәт ителми.

14. Стационар булмаган сәүдә объектының тышкы күренеше Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге тарафыннан килештерелә.

## СТАЦИОНАР БУЛМАГАН СӘҮДӘ ОБЪЕКТЫН АУКЦИОН УЗДЫРМЫЙЧА УРНАШТЫРУГА ШАРТНАМӘ ТӨЗҮ ТӘРТИБЕ

15. Урнаштыруга шартнамә аукцион уздырмыйча түбәндәге очракларда төзелә:

1) стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга элек төзелгән шартнамә буенча үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәгән Хуҗалык итүче субъект тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы белән каралган элеккеге урынында урнашса, стационар булмаган сәүдә объектын яңа вакытка урнаштыру;

2) элек төзелгән 2015 елның 1 мартына гамәлдә булган һәм стационар булмаган сәүдә объекты урнаштыруны күздә тоткан җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе буенча үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәгән Хуҗалык итүче субъект тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектын элеккеге урынына урнаштыру;

шартнамә гамәлдә булган чорда түләү буенча булган бурыч (шул исәптән пеня), шулай ук стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү турында гариза бирелгән вакытка җир кишәрлегеннән фактта файдалануга түләү буенча бурыч булуы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга элек төзелгән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе буенча йөкләмәләрнең тиешенчә үтәлмәве булып тора;

3) әлеге Тәртип кабул ителгәннән соң расланган стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру схемасына кермәгән стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруны күздә тоткан җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре 2015 елның 1 мартына гамәлдә булган, шулай ук җирле үзидарә органы түбәндәге карарларны кабул иткәндә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамәнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылганда, Хуҗалык субъектларына компенсация (ирекле) урыны бирү:

киоск - эчендә сатучының бер эш урыны җиһазландырылган һәм анда товар запасын саклау гамәлгә ашырыла торган, сәүдә залы булмаган ябык мәйданлы корылмадан торган стационар булмаган сәүдә объекты;

сәүдә галереясе - бердәм архитектура стилендә эшләнгән җылылыкны изоляцияләү функциясен үтәмәгән яктылык үткәрүчән вакытлы бер түбә астында берләшкән сатып алучылар өчен тоткарлыксыз үтеп керүне тәэмин итә торган бер-берсенә каршы симметрияле рәвештә урнашкан, әмма саны биштән дә артмаган махсус павильоннар яки киосклар җыелмасыннан торган стационар булмаган сәүдә объекты;

сәүдә автоматы (вендинг автоматы) - сатучы катнашыннан башка җайланма урнашкан урында кулланучылар тәргәгендә сату, түләү һәм данәләп сатыла торган товарлар бирү процессларын автоматлаштыру өчен билгеләнгән техник җайланмадан торган стационар булмаган сәүдә объекты;

лоток - сәүдә залы һәм товарлар саклау өчен урыны булмаган, мәйданында бер сәүдә көненә товар запасы урнаштырыла торган киштә белән җиһазландырылган, бер эш урынына исәпләнгән, җиңел төзелүче сүтеп җыела торган конструкциядән гыйбарәт стационар булмаган сәүдә объекты;

палатка - сатучыларның бер яки берничә эш урыны өчен һәм бер көнгә товар запасын урнаштыру өчен билгеләнгән, киштә ягыннан ябык булмаган, эчке мәйданны барлыкка китерә торган җиңел төзелүче сүтеп җыела торган конструкциядән гыйбарәт стационар булмаган сәүдә объекты;

кавын-карбыз сату мәйданчыклары (бахчевой развал) - сезонлы бахча культураларын сату өчен билгеләнгән аерымланган ачык мәйданчык яки урнаштырылган сәүдә палаткасы рәвешендәге махсус җиһазланган вакытлы корылмадан торган стационар булмаган сәүдә объекты;

чыршы базары - Яңа елда (Раштуада) табигый ылыслы агачларны һәм ылыслы агачларның ботакларын сату өчен аерымланган ачык мәйданчык рәвешендә махсус җиһазландырылган вакытлыча корылган стационар булмаган сәүдә объекты;

сезонлы кафелар, туңдырма һәм салкынча эчемлекләр өчен урам суыткычлары (көпчәкләрдә түгел) - эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары тарафыннан кулланыла торган төрле урыннарда берничә тапкыр куллану мөмкинлеге булган җиңел, шул исәптән сүтеп җыела торган конструкцияләрдән гыйбарәт сәүдә объектлары.

## СТАЦИОНАР БУЛМАГАН СӘҮДӘ ОБЪЕКТЛАРЫН УРНАШТЫРУГА ҺӘМ АНЫҢ ТЫШКЫ КҮРЕНЕШЕНӘ ТАЛӘПЛӘР

6. Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан расланган Шубан авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы (алга таба - Схема) белән билгеләнгән урыннарда гамәлгә ашырыла.

7. Стационар булмаган сәүдә объектлары урамнарның һәм юлларның кызыл линияләре чикләрендә урнашкан очракта, аларны, тротуар буйлап ирекле үтү юлы киңлеген стационар булмаган сәүдә объектының иң кырый элементыннан алып юл читенә кадәр 1,5 метрдан ким булмаган киңлектә саклап, тротуар чикләрендәге таш җәелгән (асфальтланган) мәйданчыкта гына урнаштыру мөмкин.

8. Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштырганда җәяүлеләр үтү өчен комачаулыклар тудырмый торган автотранспорт керү өчен уңайлы урын булырга тиеш.

- стационар булмаган сәүдә объектын урнаштырган очракта күрсәтелгән эшләрне башкаруга тоткарлык ясалган очракта, автомобиль юлларын ремонтлау һәм (яисә) реконструкцияләү зарурлыгы турында;

- автомобиль юлларын төзекләндерү элементларының саклагыч юл корылмаларын урнаштыру буенча эшләрне башкару турында;

- муниципаль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын яки линия объектларын урнаштыру турында;

- федераль законнарда каралган башка нигезләр буенча.

4) аяк киеме ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү өчен стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру. Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга ике һәм аннан да күбрәк гариза булган очракта, шартнамә сатулар (торглар) нәтиҗәләре буенча төзелә;

5) басма продукция сату буенча стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру. Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга ике һәм аннан да күбрәк гариза булган очракта, шартнамә сатулар (торглар) нәтиҗәләре буенча төзелә;

6) күрсәтелгән стационар сәүдә объекты, шул исәптән җәмәгать туклануы объекты урнашкан бина, төзелеш, корылма астындагы җир кишәрлеге белән чиктәш булган җир кишәрлегендә стационар булмаган сәүдә объекты урнаштырганда, стационар сәүдә объекты милекчесе (арендаторы) тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектын, шул исәптән җәмәгать туклануы объектын урнаштыру.

16. Сатулардан башка урнаштыруга шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

2) Хуҗалык итүче субъект тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр булган гариза бирү;

3) әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы таләпләргә туры килә торган элек бирелгән гариза булуы.

17. Әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы каралган очракларда Хуҗалык итүче субъект Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитетына аның белән урнаштыруга Шартнамә төзү турында гариза белән мөрәҗәгать итә. Гариза Хуҗалык итүче субъект тарафыннан шәхсән яки почта аша тапшырылырга мөмкин.

Күрсәтелгән гариза нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты мондый гариза кергән көннән соң 10 эш көне эчендә Хуҗалык итүче субъект гаризасының әлеге Тәртипнең 15 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә һәм урнаштыруга Шартнамә төзү яки урнаштыруга Шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында гаризада күрсәтелгән реквизитлар буенча хәбәр итә.

Урнаштыруга Шартнамә төзү турында карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты гариза бирүчегә кул куелган урнаштыруга Шартнамәне бирә.

Урнаштыруга Шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, урнаштыруга Шартнамә төзүдән баш тарту турында хат бирә.

СТАЦИОНАР БУЛМАГАН СӘҮДӘ ОБЪЕКТЫН УРНАШТЫРУГА ШАРТНАМӘНЕ ӨЗҮ ТӘРТИБЕ

18. Урнаштыруга Шартнамәне өзү яклар килешүе буенча, суд карары буенча яисә урнаштыруга Шартнамә төзүче якның граждан законнары нигезендә Шартнамәне үтәүдән берьяклы баш тартуына бәйле рәвештә рөхсәт ителә.

19. Урнаштыруга Шартнамәне өзү өчен нигезләр булган очракта, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитеты Хуҗалык итүче субъектка урнаштыруга Шартнамәне өзү өчен нигезләр ачыклanganнан соң өч көн эчендә урнаштыруга Шартнамәне өзү турында хәбәрнамә җибәрә. Хуҗалык итүче субъект күрсәтелгән хәбәрнамәне алган көннән алып 30 көн эчендә җир кишәрлегеннән үзенең стационар булмаган объектын алырга тиеш.

20. Хуҗалык итүче субъект тарафыннан хәбәрнамәдә күрсәтелгән вакытта ирекле тәртиптә объектны сүтү башкарылмаган очракта, Башкарма комитет мәҗбүри сүтүне гамәлгә ашыра.

21. Башкарма комитет инициативасы буенча түбәндәге очракларда Шартнамә берьяклы тәртиптә өзелергә мөмкин:

1) әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы 3 пунктчасында каралган очракларда;

2) хуҗалык итүче субъект ике айдан артык рәттән урнаштыру өчен түләү кертмәгән очракта. Шул ук вакытта урнаштыруга Шартнамәне өзү турындагы хәбәрнамә хуҗалык итүче субъектка Шартнамәне өзү фаразлана торган датага кадәр 30 календарь көн кала җибәрелергә тиеш;

3) Хуҗалык субъекты стационар булмаган сәүдә объектын максатчан куллану турында Шартнамәнең шартларын бозуны яисә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга Шартнамәдә билгеләнгән стационар булмаган сәүдә объекты мәйданын арттыруга бәйле хокук бозуны бетерү хакында күрсәтмә 30 календарь көне дәвамында үтәлмәгән очракта. Күрсәтелгән күрсәтмәгә шикаять биргәндә, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга Шартнамәне өзү өчен нигез булып хуҗалык итүче субъектка мондый күрсәтмәне законсыз дип тану турындагы таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту хакында законлы көченә кергән суд карары тора.

4) хуҗалык итүче субъектта салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш булмаган бурычлар булган очракта.